КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 декабрь г.Казань № 1273

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын бирү тәртибе турында» 2007 ел, 20 сентябрь, 475 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын бирү тәртибе турында» 2007 ел, 20 сентябрь, 475 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 15 ноябрь, 936 нчы; 2013 ел, 10 июнь, 395 нче; 2013 ел, 2 ноябрь, 836 нчы; 2016 ел, 19 апрель, 239 нчы; 2017 ел, 28 июнь, 447 нче; 2019 ел, 30 апрель, 372 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.3 нче пунктның «ж» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ж) торак урында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар санын раслый торган мәгълүматлар.»;

4.5 нче пунктның «е» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«е) торак урында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар санын раслый торган мәгълүматлар;»;

6.4 нче пунктка «нормалары буенча» сүзләреннән соң «, әмма кимендә 24 квадрат метр» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин